КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 5 май г.Казань № 662

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе мәсьәләләре» 2007 ел, 12 ноябрь, 622 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 10 декабрь, 706 нчы, 2007 ел, 29 декабрь, 800 нче, 2009 ел, 23 гыйнвар, 35 нче, 2009 ел, 11 декабрь, 849 нчы, 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче, 2011 ел, 31 гыйнвар, 56 нчы, 2011 ел, 5 март, 177 нче, 2011 ел, 18 ноябрь, 947 нче, 2012 ел, 19 июнь, 524 нче, 2012 ел, 5 октябрь, 833 нче, 2013 ел, 19 ноябрь, 893 нче, 2014 ел, 21 апрель, 262 нче, 2014 ел, 9 сентябрь, 656 нчы, 2014 ел, 24 декабрь, 1018 нче, 2015 ел, 4 июнь, 409 нчы, 2015 ел, 7 август, 575 нче, 2016 ел, 3 июнь, 370 нче, 2017 ел, 20 апрель, 232 нче, 2017 ел, 26 сентябрь, 719 нчы, 2018 ел, 27 сентябрь, 869 нчы, 2018 ел, 10 декабрь, 1100 нче, 2018 ел, 29 декабрь, 1295 нче, 2020 ел, 27 май, 426 нчы, 2020 ел, 1 сентябрь, 770 нче, 2020 ел, 12 ноябрь, 1019 нчы, 2021 ел, 20 март, 153 нче, 2021 ел, 20 июль, 618 нче, 2021 ел, 10 август, 699 нчы, 2021 ел, 27 декабрь, 1295 нче, 2022 ел, 11 март, 216 нчы, 2022 ел, 2 ноябрь, 1168 нче, 2022 ел, 26 декабрь, 1416 нчы, 2023 ел, 16 март, 255 нче, 2023 ел, 16 июнь, 721 нче, 2023 ел, 24 август, 1013 нче, 2024 ел, 1 июль, 487 нче, 2024 ел, 27 декабрь, 1228 нче, 2025 ел, 3 февраль, 58 нче, 2025 ел, 5 июнь, 410 нчы, 2025 ел, 19 июль, 533 нче, 2026 ел, 13 гыйнвар, 6 нчы, 2026 ел, 31 март, 322 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.1 пунктта:

4.1.2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.2. Капиталь төзелеш объектларын үз көчләрең белән төзегәндә, реконструкцияләгәндә экспертиза, үлчәү эшләре үткәрергә, шулай ук кирәк булган очракларда капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә

экспертиза, тикшерүләр, үлчәү эшләре, башкарылган эшләрнең һәм кулланыла торган төзелеш материалларының лаборатор һәм башка сынауларын үткәрү максатларында Татарстан Республикасы бюджетында каралган акчалар исәбеннән һәм финанслауның башка чыганакларыннан махсуслаштырылган оешмалар, фәнни-тикшерену һәм проект институтлары, югары квалификацияле белгечләр (экспертлар), галимнәр җәлеп итәргә.

Төзелешне, реконструкцияләүне гамәлгә ашыручы зат капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә экспертизалар, үлчәү эшләре өчен түләүне кертә. Әлеге акчалар төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеге буенча өстәмә чараларны финанслау өчен Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенә бюджет керемнәре администраторының шәхси счетына күчерелә.»;

6.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.1. Инспекциянең мөлкәтен формалаштыру, карап тоту һәм финанс ресурслары чыганаклары Татарстан Республикасы бюджеты акчалары була. Капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә экспертиза, үлчәү чыгымнарын каплауга кергән акчалар төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеге буенча өстәмә чараларны финанслауга җибәрелә.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүдә катнашучы оешмалар һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә вәкаләтле экспертлар күрсәтә торган хезмәтләр исемлеген раслау турында» 2011 ел, 13 август, 675 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 11 июль, 597 нче, 2023 ел, 7 июнь, 692 нче, 2023 ел, 07 июль, 793 нче, 2024 ел, 29 июль, 600 нче, 2024 ел, 26 сентябрь, 835 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүдә катнашучы оешмалар һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә вәкаләтле экспертлар күрсәтә торган хезмәтләр исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

12 пунктта «экспертизалар,» сүзен төшереп калдырырга;

13 пункт үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин